ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.02.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 420**

Зеленодольск шәһәре территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясындагы 2 өлеше, 98 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында( http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 нче мартыннан законлы көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ҖИР КОНТРОЛЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН ТИКШЕРҮ КӘГАЗЕ (КОНТРОЛЬ СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ) ФОРМАСЫ**

______________________________________________________________

(муниципаль җир контроле органы исеме)

МУНИЦИПАЛЬ ҖИР КОНТРОЛЕ
(муниципаль контроль төре)

Зеленодольск шәһәре территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)

1. Юридик затның атамасы, индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) ______________________________________________

2. Тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны һәм (яисә) юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган җир кишәрлекләре ______________________________________________

3. Юридик затның, индивидуаль эшкуарның планлы тикшерүен үткәрү турында күрсәтмәнең реквизитлары:______________________________________________

(юридик затның, индивидуаль эшкуарның планлы тикшерүен үткәрү турында күрсәтмә номеры, датасы)

4. Тикшерүнең исәп номеры һәм тикшерүнең исәп номерын бердәм реестрда бирү датасы______________________________________________

(тикшерүнең исәп номеры һәм бердәм тикшерүләр реестрында бирү датасы күрсәтелә)

5. Тикшерү кәгазенең формасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының ________________________номеры карары белән расланды

Планлы тикшерү уздыручы һәм тикшерү кәгазен тутыручы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары ______________________________________________

7. Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге, аларга җаваплар тикшерү предметын тәшкил итүче мәҗбүри таләпләрнең юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үтәлүе яисә үтәлмәве турында бер үк мәгънәдә таныклый:

| № т/б | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган мәсьәләләр | Мәҗбүри таләпләр куелган структур | Сорауларга җаваплар |
|---|---|---|---|

| | | берәмлекләрне күрсәтеп, норматив хокукый актларны реквизитлары | Әйе | Юк | Таләп кагылмый |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тикшерелә торган юридик зат яисә индивидуаль эшкуар билгеләнгән максатчан билгеләнеш һәм (яисә) рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә җир кишәрлеге кулланамы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 7 статьясындагы 2 пункты, 42 статьясы | | | |
| 2 | Тикшерелә торган юридик затның яисә индивидуаль эшкуарның Россия Федерациясе законнарында каралган файдаланыла торган җир кишәрлегенә (файдаланыла торган җир кишәрлекләре, җир кишәрлекләренең өлешләренә) хокуклары бармы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты | | | |
| 3 | 2015 елның 13 июлендәге «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 218-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә файдаланыла торган җир кишәрлегенә (файдаланыла торган җир кишәрлекләренә, җир кишәрлегенең бер өлешенә) хокук теркәлгәнме, яисә идарә итү хокукына чикләү теркәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 26 статьясындагы 1 пункты, Россия Федерациясе Граждан кодексының 8.1 статьясы | | | |
| 4 | Тикшерелә торган юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан кулланыла торган җир кишәрлеге мәйданы, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларында күрсәтелгән мәйданга туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты, 26 статьясындагы 1 пункты | | | |
| 5 | Тикшерелә торган юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган җир кишәрлеге чикләренең борылыш нокталары урыны, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләренең торышы турындагы белешмәләргә туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 6 статьясындагы 3 пункты, 25 статьясындагы 1 пункты | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләреннән) файдалану җирләрне яисә җир кишәрлекләрен файдалануга рөхсәт нигезендә мондый җирләр яисә җир кишәрлекләре чикләрендә туфракның уңдырышлы катламын бозуга китерсә, җир яисә җир кишәрлекләре рөхсәт ителгән файдалану өчен яраклы хәлгә китерелгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.35 статьясындагы 1 пунктчасы | | | |
| 7 | Сервитутның гамәле туктатылган очракта, тикшерелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан сервитут билгеләнгән очракта, җир кишәрлеген куллану өчен яраклы халәткә китерү бурычы рөхсәт ителгән куллану нигезендә башкарыламы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.25 статьясындагы 1 пунктының 9 пунктчасы | | | |
| 8 | Тикшерелүче юридик зат тарафыннан (дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, дәүләт һәм муниципаль учреждение (бюджет, казна, автоном), казна предприятиесе, Россия Федерациясе Президентының үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан тарихи мирас үзәгеннән тыш)җир кишәрлегеннән (җир кишәрлекләреннән) даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) арендалау хокукына яисә җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) милек итеп алу бурычын яңадан рәсмиләштерү бурычын үтәдеме? | 2001 елның 25 октябрендәге "Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында"137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Җир кишәрлеген законнарда билгеләнгән срокларда файдалануның (үзләштерүнең) мәҗбүрилеге турындагы таләп үтәлдеме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 42 статьясы, Россия Федерациясе Граждан кодексының 284 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 45 статьясындагы 2 пункты | | | |

"_" ________ 20__ ел
(тикшерү кәгазе тутыру дата күрсәтелә)

___________________________ ______________ __________________________

(тикшерү кәгазе тутыручы вазыйфаи зат)

(имза)

(тикшерү кәгазе тутыручы затның фамилиясе, атасының(булса) исеме